СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 3-19 от «26» декабря 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылы җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылы җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга (кушымта).

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына ( Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлегенә) әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылы җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расланганнан соң биш көн эчендә территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылы җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен“Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалтты дип танырга:

- 2018 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылы җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 5-29 номерлы карары;

-2019 елның 23 июлендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылы җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 15-34 номерлы карары;

-2020 елның 30 июнедәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылы җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 19-39 номерлы карары;

- 2021 елның 10 июнендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылы җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 4-7 номерлы карары.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П. Иванов